**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2022елның 7 сентябре** **65-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, 2022 елның 9 августындагы гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2022 елның 10 августындагы бәяләмәне карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын рasларга (1 кушымта).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык - Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Лаеш шәһәре Советы рәисе** **И.Ф.Зарипов**